Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге составына керүче Трой-Урай авыл җирлегендә гражданнар җыены

**КАРАРЫ**

27 ноябрь 2020 ел № 3

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Трой-Урай авыл җирлеге составына керүче Трой-Урай авылындагы гражданнар җыены нигезендә **карар кабул ителде**:

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлегенең Трой-Урай авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә;

2. Салым акчасын түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:

1. Троицкий Урай авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә юлларны ремонтлау һәм карап тоту.
2. Троицкий Урай, Гремячка авыллары торак пунктларында православие зиратларын төзекләндерү эшләрен тәмамлау.
3. Троицкий Урай һәм Гремячка авылларында су линиясен ремонтлау.
4. 2 данә запас су насослары сатып алу.
5. Авыл җирлеге торак пунктларына энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру.
6. Гремячка авылы Яшьләр урамына янгын гидранты урнаштыру.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Трой Урай авылы Прикамкая урамы, 9 йорт, Мәктәп урамы 13 йорт, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Гремячка авылы Александрова урамы, 24 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Сафин Р.Х.

Трой-Урай авыл җирлеге башлыгы Сафин Р.Х.